РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 29 октябре Кукмара ш. № 80

Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме –Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» (текстта алга таба – район), кыскартылган исеме – Кукмара муниципаль районы.

1.2. 6 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктын өстәргә:

«9.1) шәһәр һәм авыл торак пунктларыннан читтәге муниципаль районнар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;»;

б) 39 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«39) комплексլы кадастр эшләрен башкаруны федераль закон нигезендә оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;»

1.3. 7 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Районның җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль район музейларын төзү;

2) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнашу;

3) муниципаль район территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

4) муниципаль район территориясендә Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтү;

5) 2008 елның 31 декабренә торышы буенча алар карамагындагы югары белем бирү муниципаль белем бирү оешмаларын гамәлгә куючы функцияләрен гамәлгә ашыру;

6) туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;

7) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык итүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтү;

8) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре оешмалары тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтү;

9) «Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» Федераль законда каралган чараларны гамәлгә ашыру;

10) авылара территориядә урнашкан торак пунктта нотариус булмаган очракта законнарда каралган нотариаль гамәлләр кылу;

11) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча федераль законнар нигезендә чаралар кабул ителүне тикшереп тору;

12) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру;

13) инвалидларның, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын үстерүгә, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм итү;

14) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру;

15) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр әлеге вазыйфаны биләгән вакытка торак урыны бирү;

16) алкоголь, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;

17) муниципаль янгын сагын булдыру.»;

1.4. 8 статьяда:

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24) комплекслы кадастр эшләрен башкаруда федераль закон нигезендә катнашу;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«25) карарлар кабул итү һәм җирлекләр территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез мөлкәт объектларының хокук ияләрен ачыклау чараларын үткәрү, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына кертү өчен күчемсез мөлкәт объектларының хокук ияләре турында белешмәләр җибәрү.»;

1.5. 30 статьяның 7 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

7) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының шулар нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклычит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы булу;»;

1.6. 43 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының шулар нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклычит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы булу;»

1.7. 47 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитет районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) муниципаль район музейларын төзи;

2) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнаша;

3) муниципаль район территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

4) муниципаль район территориясендә Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтә;

5) 2008 елның 31 декабренә торышы буенча алар карамагындагы югары белем бирү муниципаль белем бирү оешмаларын гамәлгә куючы функцияләрен башкара;

6) туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

7) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык күрсәтүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтә;

8) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның гомумроссия иҗтимагый берләшмәләре оешмалары тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтә;

9) «Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» Федераль законда каралган чараларны гамәлгә ашыра;

10) авылара территориядә урнашкан торак пунктта нотариус булмаган очракта законнарда каралган нотариаль гамәлләр кылуны оештыра;

11) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыра, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллана һәм оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча федераль законнар нигезендә чаралар кабул ителүне тикшереп тора;

12) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра;

13) инвалидларның, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм итә;

14) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра;

15) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр әлеге вазыйфаны биләгән вакытка торак урыны бирә;

16) алкоголь, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра;

17) муниципаль янгын сагын төзи.».

1.8. 52 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының шулар нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара

шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклычит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы булу;»;

1.9. 82 статьяның 7 өлешенә түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзацны өстәргә:

«Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү буенча юнәлешләрен билгеләүче документлар;»;

1.10. 91 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Район уставы, район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары, дәүләт теркәве узганнан соң, рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм, алар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң, үз көченә керә. Район башлыгы теркәлгән уставны, район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карарын муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан муниципаль берәмлек уставы турында, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына кертү хакында «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган хәбәрнамә кергән көннән соң җиде көн эчендә бастырырга (халыкка җиткерергә) бурычлы».»

2. Әлеге карар, үз көченә керүнең башка вакытлары законнар белән каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, интернет-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев